КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 декабрь г.Казань № 1152

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе

Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Объектларны урнаштыру түләүле гамәлгә ашырыла. Түбәндәге объектлар чыгарма булып торалар:

территорияне төзекләндерү элементлары, шул исәптән кече архитектура формалары, территорияне уңайлаштыруның состав өлеше буларак кулланыла торган капиталь булмаган стандарт булмаган төзелмәләр һәм корылмалардан, реклама конструкцияләреннән тыш;

пандуслар һәм халыкның аз мобиль төркемнәре хәрәкәтен тәэмин итә торган башка җайланмалар, биналар, корылмаларның конструктив элементларына карый торган пандуслар һәм җайланмалардан тыш;

мәгълүмат такталарын (стелаларны) һәм флагштокларны кертеп, геодезия, межалау, кисәтү билгеләре һәм башка билгеләр;

урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган саклаучы корылмалар;

урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган үтү юллары, шул исәптән трасса буйлап, һәм керү юллары;

янгын сулыклары һәм янгын сүндерү чараларын туплау урыннары;

парга әйләндерү өчен буалар;

35 кВ кадәр көчәнеш классы булган электр тапшыру линияләре, шулай ук алар белән бәйле трансформатор ярдәмче станцияләре, бүлү пунктлары һәм урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыручы башка җайланмалар;

барлык төрдәге җылылык челтәрләре, урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен кертеп.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин